# Ризаэтдин Фәхретдин – иң күренекле затларның берсе

## Бала чагы

Ризаэтдин Фәхретдин 1859 елның 17 гыйнварында Самара губернасының Бөгелмә өязе (хәзерТатарстанның Әлмәт районы) Кичүчат авылында туган. Әтисе Фәхретдин Сәйфетдин улы шул авылның имамы булган. Ризаэтдин иң беренче сабакларын 5-6 яшьлек вакытында әнисе Мәһүбә абыстайдан алган. 1867 елның көзеннән 1868 елның язына кадәр, җизнәсе Гыйльман Кәримигә ияреп барып, Чистай мәдрәсәсендә укыган. Гыйльман хәзрәт Миңлебай авылына имам итеп билгеләнү сәбәпле, Ризаэтдин башка елларда ерактагы Чистайга укырга бармаган, үзләренә якынрак Түбән Шәлчәле авылы мәдрәсәсенә 1869 елда барып, анда нигезле белем алган. Мәдрәсәнең югары сыйныфларына җиткәч, кечерәк сыйныф шәкертләренә үзе дә сабак укыта башлаган. 1889 елның язына хәтле ул Шәлчәле мәдрәсәсендә хәлфәлек итеп, шәкертләргә белем биргән.

## Казан

Ризаэтдин Фәхретдин 1886 елда Казанга сәяхәт итеп, заманының олуг тарихчысы һәм дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани белән очраша. Аннан соң, 1887 елның 19 июнендә Уфада имтихан тапшырып, имам-хатыйплык шәһадәтнамәсе – указ ала. Шул ук 1887 елда Ризаэтдин Фәхретдиннең гарәп теле грамматикасы турында язган беренче китабы басылып чыга.

## Петербург

1888 елның җәендә Петербурга барып, анда ике ай чамасы яши, заманының танылган ислам философы Җәмалетдин Әфгани белән очраша. Мондый күренекле затлар белән очрашулары һәм аралашулары Ризаэтдин Фәхретдингә бик зур тәэсир ясаган. Ул Шиһабетдин Мәрҗани, Җәмалетдин Әфгани һәм Исмәгыйль Гаспралыны үзенең рухи остазлары дип санаган.

## Илбәк авылы

1889-1891 елларда Ризаэтдин Фәхретдин Бөгелмә өязенең Илбәкавылында имам һәм мөдәррис вазифаларын башкарган. 1891 елда ахунлык дәрәҗәсен алган.

## Уфа, казыйлык

Уфа шәһәрендәге Мәхкәмәи Шәргыягә (Диния нәзарәтенә) беренче мәртәбә 1891 елда казый итеп сайлана һәм өч ел саен шул ук вазифага кабат-кабат сайланып, 1906 елга хәтле казыйлык хезмәтен башкара. Ризаэтдин Фәхретдиннең казыйлык вакытында башкарган иң зур эшләренең берсе – Диния Нәзарәтенең таркау хәлдәге архивын тәртипкә китерү булган. Фидакяр хезмәтләре өчен ул 1894 һәм 1897 елларда патша хөкүмәте тарафыннан көмеш һәм алтын медальләр белән бүләкләнгән.

Уфага килгәнче Ризаэтдин Фәхретдиннең берничә дәреслеге басылып чыккан була. Уфада исә ул тулаем фәнгә чумып, иҗат эшчәнлеген арттыра. Бер-бер артлы "Тәрбияле бала", "Тәрбияле ана", "Шәкертлек адәбе" кебек дәреслекләре, шулай ук "Сәлимә, яки Гыйффәт" (1899), "Әсма, яки Гамәл вә җәза" (1903) кебек әдәби җәүһәрләре, "Асар" кебек тарихи хезмәтләре нәшер ителә. 1907 елга хәтле аның барлыгы 29 исемдәге әдәби, тарихи, гыйльми педагогик, дини хезмәтләре һәм әсәрләре басылып чыккан. Аларның кайберләре дүртәр-бишәр, хәтта алты мәртәбә басылганнар. Казыйлык вазифасындагы намуслы хезмәте һәм иҗат әсәрләре белән Риза казый исеме барлык төрки-татар һәм мөселманнар арасында шөһрәт таба.

## Оренбур, "Шура" журналы

Оренбур шәһәрендә чыга башлаган "Вакыт" газетының каширләре – бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр, мөхәррире Фатыйх Кәримиләрнең чакыруы белән Риза казый 1906 елда Уфадан китә. Шул елның язында ул гаиләсе белән Оренбур шәһәренә күчеп килә һәм "Вакыт" газеты идарәсендә эшли башлый, төрле мәсьәләләргә караган мәкаләләр язып бастыра.

Бертуган Рәмиевләр 1907 елның декабрендә татар телендә яңа журнал нәшер итәргә рөхсәт алалар. "Шура" дип исемләнгән яңа журнал 1908 елның гыйнварында чыга башлый, баш мөхәррире итеп Ризаэтдин Фәхретдин билгеләнә. Журнал 1918 елда ябылганчыга хәтле Ризаэтдин Фәхретдин "Шура"ны мөхәррир буларак җитәкли. Ун ел дәвамында нәшер ителгән бу журналда аның йөзләгән мәкаләләре дөнья күргән. Тематика ягыннан алар киң даирәне – әдәбият, тарих, сәнгать, мәгариф, дини-иҗтимагый мәсьәләләр һ.б. колачлаган. Журналның искиткеч бай эчтәлекле һәм кызыклы булып чыгуы да – баш мөхәрриренең армый-талмый хезмәт итүенең матур нәтиҗәсе. Журналда эшләү чорында да ул әдәби һәм гыйльми эшчәнлеген дәвам иткән, хезмәтләре китаплар булып чыгып торган. Шул ук елларда Оренбурдаагы "Хөсәения" мәдрәсәсендә дәресләр дә укыткан.

## Совет чоры

"Шура" журналы совет хөкүмәте тарафыннан ябылганнан соң, 1918 елның язында Ризаэтдин Фәхретдин гаиләсе белән Уфага күчеп килә һәм Диния нәзарәтендә казыйлык вазифасында эшли башлый. 1921 елның 6 декабрендә мөфти Галимҗан Баруди вафат булгач, Диния нәзарәтендә мөфтилек вазифаларын башкара. 1923 елның 10 июлендә мөфти итеп рәсми рәвештә сайлап куела һәм вафатына хәтле мөфти булып хезмәт итә.

Совет хакимлеге елларында Ризаэтдин Фәхретдин авыр дини вазифасы белән берлектә гыйльми эшчәнлеген дә дәвам иткән. 1925 елдаСоветлар Берлеге Фәннәр академиясенең Ленинград шәһәрендә үткәрелгән 200 еллык тантаналарына рәсми рәвештә чакырылган һәм катнашкан булуы – аның галим буларак зур абруйга ирешкәнлеген дәлилли.

Ризаэтдин Фәхретдин 1936 елның 12 апрелендә Уфада дөнья куйган һәм 15 апрельдә шәһәрнең мөселман зиратына җирләнгән.

Дингә карата сугышчан атеистик мөнәсәбәт саклаган совет елларында казый һәм соңгы дәверендә мөфти булып эшләгәнлеге сәбәпле Ризаэтдин Фәхретдиннең исеме нахакка рәнҗетелеп, дистә еллар онытылып торган. Фәкать 1960нчы елларның ахырларында гына аның исеме матбугатта яңадан чыга башлый.

Ризаэддин Фәхреддин - мәшһүр тарихчы - галим, әдип, педагог, журналист, шәрык белгече, философ, мәгърифәтче, имам, акыллы мөфти, гадел казый, саф акыл иясе.

Р. Фәхретдинов - әдәп, әхлак, шәфкать, изгелек,итагатьлелек , кешелеклелек, намус, сафлык, пакьлек, гаделлек, яхшылык кебек күркүм сыйфатларны эченә алган хезмәтләрне эченә алган хезмәтләрне мирас итеп калдырган олы шәхесебез.

Аның “Тәрбияле ата”, “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле бала”, “Шәкертлек әдәбе”, “Гаилә”, “Нәсихәт”, “Ата әдәбе”, “Ир әдәпләре”, “Хатын әдәпләре”, “Ана әдәпләре”, “Исерткеч эчүдән котылу чаралары”, “Сәлимә, яки гыйффәт”, “Китап вә уку” һ. б. хезмәтләрен өйрәнү, һичшиксез, бүгенге коточкыч ямьсез - кеше талау, эчүчелек, наркомания, фәхишәлек, үтереш кебек күренешләрне киметер иде дип ышанасы килә.